Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районының
Борискино авыл Советы

КАРАР

24 апрель 2023 ел №65

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Борискино авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Борискино авыл җирлеге җирле үзидарәсе җирле үзидарә депутатына, сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында төгәл булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу белешмәләрне бозып күрсәтү җитди булмаган булса, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе хакында» 2020 елның 12 июлендәге 15 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Борискино авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Борискино авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Борискино авыл җирлеге җирле үзидарәсе җирле үзидарә депутатына, сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында төгәл булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу белешмәләрне бозып күрсәтү җитди булмаган булса, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе хакында» 2020 елның 12 июлендәге 15 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карарга 1 нче кушымтада:

3 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгын (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктның беренче һәм өченче абзацларында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәис) сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Борискино авылы, Үзәк ур., 61 йорт, Березовка бистәсе, Үзәк урам, 16 йорт торак пунктлар территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Борискино авыл
җирлеге башлыгы Ж.С.Илалов